# 1 нче апрель - Халыкара көлке көне



Һәр ай шикелле апрель ае да 1нче числодан башланып китә. Әмма айның башлану көненең исеме бик җитди түгел .

1 апрель**«Көлке көне»**. Көлке көне күп илләрдә билгеләнеп үтүче рәсми булмаган халыкара бәйрәм. Күпчелек илләрдә ул 1 нче апрельдә үтә. Бу бәйрәм XVI гасырдан бирле үткәрелә. Россиядә массакүләм рәвештә көлке көне беренче тапкыр Мәскәү шәһәрендә 1703 нче елда үткән.


# 1 апрель—Халыкара кошлар көне

**1 апрель көнне мәктәптә "Һәр укучыдан - бер сыерчык оясы" дип исемләнгән бәйге-гә нәтиҗә ясалды.Укучылар, укытучылар, әти- әниләр катнашкан бу бәйгедә җиңү яулаган укучыларга бүләкләр һәм Мактау грамоталары тапшырылды."Иң яхшы ясалган оя" номинациясендә беренче урынга лаек булучылар арасында 3нче сыйныф укучысы Гараев Гадел һәм 1 сыйныф укучысы Гараев Булат та бар. Бу укучыларны җиңүләре белән КОТЛЫЙБЫЗ!**




# Башлангыч сыйныфларның математика атналыгы

14-19 апрель көннәрендә мәктәбебездә башлангыч сыйныфларның математика атналыгы булып үтте. Атналык математика елына багышланды.15 апрель көнне укучылар "Өчпочмаклар" һәм "Квадратлар" командаларына бүленеп КВНда көч сынаштылар. Аңлатмаларны,логик мәсъәләләрне,ребусларны чишүдә, геометрик фигураларны тануда, саннар рәтен тулыландыруда берәүнең дә калышасы килмәде. Укучылар бик актив катнаштылар,шулай да,"Квадратлар" командасы җинде.Бәйгене файдалы һәм мавыктыргыч итеп башлангыч сыйныфлар укытучысы Гарипова Г.З. үткәрде.









Математик КВН нан күренешләр

# «Сәгатьләр»




16 апрель көнне башлангыч сыйныфлар атналыгының өченче көнен башлангыч сыйныфларның методик берләшмә җитәкчесе Гарипова Г.З. дәвам итте. Ул математика фәненә багышлап "Сәгатьләр" исемле ачык чара үткәрде. Укучылар укытучы җитәкчелегендә презентация аша сәгатьләрнең төрләре, кулланылышы турында сөйләделәр. Су,кояш, ком, ут сәгатьләре, механик, электрон сәгатьләр укучыларда зур кызыксыну уятты. Вакыт кадерен белүдә сәгатьләрнең роле ачыкланды.

# Геометрик фигуралардан сюжетлы аппликация ясау бәйгесе

<u>I урын</u>: Рахматуллина Диана, Ганина Юлия, Закиров Данияр, Саидов С.

<u>II урын</u>: Гараев Б., Мөхәмәдиева С., Саидова С., Гараев Г., Гыймадиев И., Гыйләҗиева Р.



# Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбе һәм балалар бакчасында киңәшмә

18 нче апрельдә Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбе һәм балалар бакчасында башлангыч сыйныф укытучыларының чираттагы киңәшмәсе үткәрелде. Киңәшмә "ФГОС таләпләрен гамәлгә ашыруда башлангыч мәктәп һәм балалар бакчасы арасында бәйләнеш» темасына багышланды. Беренче көн тәртибе буенча башлангыч сыйныф укытучысы Г.З.Гарипова тарафыннан икенче буын стандартлары таләпләре һәм аны үтәү барышы турындагы чыгышы тыңланды. Икенче көн тәртибе буенча Олы Кибәхуҗа мәктәбенең 2 нче сыйныф укытучысы М.А. Валеева II сыйныфта математикадан "Минут" темасына ачык дәрес күрсәтте. Укытучылар яңа дәрес темасын өйрәтүдә универсаль уку гамәлләренең башкарылу юллары белән таныштылар. Дәрес нәтиҗәле һәм файдалы үтте. Өченче көн тәртибе буенча Олы Кибәхуҗа балалар бакчасы тәрбияче Г.Х.Мингазова әзерлек төркеменә йөрүче балалар белән математикадан шөгыль үткәрде. Шөгыль барышында балалар табышмакларга җаваплар таптылар, 10 эчендә санау, исәпләү күнекмәләрен үстерүдә фикерләүгә биремнәр үтәделәр. Дүртенче көн тәртибе буенча үткәрелгән ачык дәрескә һәм ачык шөгыльгә анализ ясалды. Анализ ясауда башлангыч сыйныф укытучылары: М.А.Валеева, Г.З.Гарипова, И.Р.Шәяхмәтова, Т.М.Асманова, балалар бакчасы тәрбиячесе Мингазова Г.Х. һәм Солтангараева Г. катнаштылар. Киңәшмә эшлекле һәм файдалы төстә үтте.



**Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбе һәм балалар бакчасында үткәрелгән киңәшмә вакытында...**

# Математика патшалыгында

17 апрель көнне башлангыч сыйныф укытучысы Асманова Т.М. спортзалда 1-4 сыйныф укучылары белән берлектә «Математика патшалыгында» исемле уенсәяхәт үткәрде. Сәяхәт спорт эстафетасы формасында үтте. Укучылар саннар арасыннан зуррakларын, кечерәкләрен бик тиз аердылар, 20 эчендәге саннарны "йөгерә-йөгерә" куштылар, парларын таба- таба мисаллар эшләделәр, зирәклеккә мәсьәләләр чиштеләр, исәпләүләр белән ромашка уены уйнадылар. Уенсәяхәттә беренче булып тиешле пунктка 3 нче сыйныф укучысы Гараев Гадел һәм 2нче сыйныф укучысы Мөхәмәдиева



# Математика укытучыларының район семинары



23 нче апрель көнне Кече Кибәхуҗа төп мәктәбендә «Дәрестә тематик контрольгә һәм имтиханга әзерләүдә БДИ, ГИА форматындагы практик биремнәр» темасы астында Теләче муниципаль районы математика укытучыларының киңәшмәсе булып узды.

Киңәшмәдә мәктәбебезнең югары категорияле математика укытучысы Наилә Нуретдиновна Әхмәтҗанова 7 нче сыйныфта математика фәненнән ачык дәрес күрсәтте. Дәрескә анализ ясалды. Аннан соң Н.Н.Әхмәтҗанова һәм өстәмә белеем бирү педагогы Р.И. Шаипова тарафыннан «Геометрия һәм мода» темасына интегральләштерелгән ачык чара үткәрелде. Шулай ук киңәшмәдә I категорияле математика укытучыларының һәм математика-физика циклы методик берләшмә җитәкчесе Гөлнур Әхмәтзакиевна Галимҗанованың “Математика елы: эзләнүләр һәм нәтиҗәләр” темасына ясалган чыгышлары зур кызыксыну белән тыңланды. Ахырдан киңәшмә “БДИ һәм ГИА –2014 кә әзерлек турында» темасы астында үзенең эшен йомгаклады.

# Тукай - безнең күңелләрдә

26 апрель көнне мәктәбебездә китапханәче Нигъмәтҗанова Х.Н. тарафыннан халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайның 128 еллыгына багышлап "Тукай безнең күңелләрдә" исемле шигырь бәйрәме үткәрелде. Бәйрәмдә укучылар Тукай шигъриятенә багышлап чыгарылган видео карадылар, шагыйрьнең үлемсез шигырьләрен сөйләделәр, 1,3 сыйныф укучылары Булат һәм Гадел Гәрәевлар "Кызыклы шәкерт" , Рахматуллина Диана һәм Гыймадиев Илүс "Бала белән күбәләк" шигырьләрен сәхнәләштерделәр, укучыларыбыз шулай ук "Туган тел" шигырен татар, инглиз, рус телләрендә сөйләделәр. 5 сыйныф укучылары чарада аеруча актив катнашты. Рахматуллина Энҗе "Кышкы кич", Даутова Гөлшат "Эшкә өндәү" шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйләделәр, Закирова Алинә исә "Эш беткәч уйнарга ярый" шигырен рәсемдә бик матур итеп сурәтләгән.



Шигырь бәйрәме күмәкләшеп "Туган тел" җырын башкару белән тәмамланды. Тукай безнең күңелләрдә булуына тагын бер тапкыр инандык.




**26 апрель көнне Теләче мәдәният йортында узган “Созвездие-Йолдызлык-2014” республикакүләм сәнгать фестиваленең зона һәм республика турларында җиңү яулаган яшь талантлар концерты булып үтте. Яшь талантлар арасында конферанс жанрында чыгыш ясаучы– апалы-сеңелле Диана һәм Энҗе Рахматуллиналар да бар. Алар Дипломга лаек булдылар. Афәрин, котлыйбыз!**

## 26 апрель-урман утырту көне

**Республикабызда урман утырту көне үткәрелде. Урманнардан шактый читтә урнашсак та, без дә бу чарадан читтә калмыйбыз. Мәктәбебез белән агач утырту өмәсенә чыктык. Мәктәп бакчасына чиеләр, миләш, алмагачлар утырттык.**



## Туган ягым- яшел бишек



"Татмедиа" ААҖ, "Чын мирас" журналы редакциясе, Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге Теләче муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге белән берлектә Теләче районы Олы Мәтәскә урта мәктәбендә "Туган ягым-яшел бишек" исемле төбәкара фәннигамәли укытучылар конференциясе үткәрде.

Конференциядә мәктәбебезнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Мөхәммәдиева Н.Д. "Шәхесләребез- туган ягыбыз горурлыгы" секциясендә "Якташыбыз Морат Мостафин - Татарстан һәм Украинаның уртак горурлыгы" темасына уңышлы чыгыш ясаганы өчен II дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде , тарих укытучысы Рахматуллина А.Ә. "Төбәк тарихы" секциясендә "Туган ягымның үткәне данлы, киләчәге өметле" темасына чыгыш ясап катнашкан өчен Дипломга ия булды.